Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
Карары

29 гыйнвар 2020 ел № 98

Карда йөрү чаналарында (снегоходларда)
кросс буенча Россия кубогын оештыру һәм
үткәрү турында

Әлмәт муниципаль районында спортның техник төрләрен үстерү һәм популярлаштыру максатыннан

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 29 февралендә "Экстрим-парк" территориясендә Әлмәт шәһәрендә карда йөрү чаналарында (снегоходларда) кросс буенча Россия Кубогын үткәрергә.

2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлегенә (Баһауов А.И.) әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә 2020 елның 29 февралендә 09:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр хәрәкәт иминлеген тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге (Зарипова Л. Н.) халыкка карда йөрү чаналарында (снегоходларда) кросс буенча Россия кубогын үткәрү турында хәбәр итәргә.


4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С. В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның «29» гыйнвар № 98 карарына
1 нче кушымта




Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева